ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) әлеге статьяның 2 өлешендәге 7 һәм 9 пунктларында каралган очраклардан тыш, урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, арендага (шул исәптән тиешле торгларны оештыру һәм үткәрү), түләүсез файдалануга бирү, шулай ук, дәүләт табигать тыюлыклары һәм милли парклар чикләрендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләреннән тыш, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләрен төзү (шул исәптән тиешле торгларны оештыру һәм үткәрү); даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын туктату турында карарлар кабул итү, урман фонды җирләре чикләрендәге урман кишәрлекләренә карата сервитутлар билгеләү хакында килешүләр төзү; урман фонды җирләре чикләрендә җир кишәрлекләрен бирүне алдан килештерү турында карарлар кабул итү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $13^7$ пункт өстәргә:

«$13^7$) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, дәүләт милкендәге җирләрдән җир кишәрлеге булдырганда аның территориянең кадастр планында урнашу схемасын килештерү;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $13^{8}$ пункт өстәргә:

«$13^{8}$) дәүләт кадастр исәбен алып баручы һәм хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органга дәүләт кадастр исәбенә алу турындагы, шул исәптән җир кишәрлекләре чикләрен төгәлләштергәндә, һәм (яисә) урман законнары нигезендә урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләре булган җир кишәрлекләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алу хакындагы гаризалар белән мөрәҗәгать итү;»;

2) 5 статьяның 1 өлешендә «аукцион» сүзен «торглар» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 09 июнь
№ 40-ТРЗ